**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

Чернышев урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Матюшино авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча уздырылган ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында БӘЯЛӘМӘ**

**«14» май 2026 ел**

Ачык тыңлаулар кешенең уңайлы яшәү шартларына булган хокукларын, җир участоклары һәм капиталь төзелеш объектлары хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау максатында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ нче номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставына, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2018 елның 12 ноябрендәге 61-РС нче номерлы карары белән расланган (Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2019 елның 11 декабрендәге 96-РС нче номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) ««Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә ачык тыңлауларны (җәмәгатьчелек фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында»гы Нигезләмәгә, Татарстан Республикасы Кабинет Министрлыгының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне кабат бүлешү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2023 елның 29 декабрендәге 1743 нче номерлы карары нигезендә үткәрелде.

Ачык тыңлауларда катнашучылар ачык тыңлауларны үткәрү сроклары, проектның мәгълүмати материаллары, проект материаллары экспозициясен үткәрү сроклары һәм урыны, ачык тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәрү датасы, урыны һәм вакыты, проект буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр бирү тәртибе турында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2026 елның17 апрелендәге 3648/исх номерлы белдерүе аша хәбәрдар ителде.

Матюшино авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар башлану турында 2026 елның17 апрелендәге 3648/исх номерлы белдерү түбәндәгечә бастырып чыгарылды (халыкка җиткерелде):

1. 2026 елның17 апрелендә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталындагы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында;

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Матюшино авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында.

**Ачык тыңлауларны оештыручы:** Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты.

**Рәислек итүче:** Карсалов Алексей Петрович – Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы.

**Ачык тыңлаулар сәркатибе:** Миңнуллина Надия Илдар кызы – Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Матюшино авыл җирлеге Башлыгы, Башкарма комитеты җитәкчесе.

Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы бәяләмә Матюшино авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча 13.05.2026 елгы ачык тыңлаулар протоколы нигезендә төзелде.

Ачык тыңлауларда 3 кеше катнашты.
Ачык тыңлаулар барышында сораулар һәм искәрмәләр кермәде.

**Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре:**

1. Ачык тыңлауларны узган дип танырга;

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Матюшино авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проектын, 2026 елның 13 маендагы ачык тыңлаулар протоколын, шулай ук әлеге бәяләмәне проектны ахыргы раслау өчен Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрлыгына юлларга;

3. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә гамәлдәге законнарга ярашлы әлеге бәяләмәдән өземтәләр бирүне гамәлгә ашырырга.

**Ачык тыңлаулар рәисе:** __________________________ Карсалов А.П.

**Ачык тыңлаулар сәркатибе:** __________________________ Миңнуллина Н.И.